**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

09.07.2021ел — № 198

«2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының 2014елның 28 ноябрендәге 841 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2015-2023елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 21 июнендәге 485 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2015 - 2023 елларга Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 28 декабрендәге 841 номерлы карарына (2016 елның 21 мартындагы 82 номерлы, 27.12.2018елның 27 декабрендәге 448 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге 281 номерлы, 29.06.2020 елның 29 июнендәге 204 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Программа исемендә, шулай ук 1 пунктларда «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

2. Күрсәтелгән карар белән расланган «2015-2023елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында: - программа исемендә «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга.

3. Муниципаль программа паспортында:

- «муниципаль программа исеме» юлында «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

- «Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга;

«Программаны бүлү юлы белән финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын еллар буенча түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| **Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары** | **Чаралар җирле үзидарә органнарын тотуга каралган муниципаль берәмлек бюджеты акчалары чикләрендә 01.00 «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге буенча 325 000 сум күләмендә уздырыла** | |
| | Ел | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының җирле бюджеты акчалары |
| | 2015 | 19,0 |
| | 2016 | 24,0 |
| | 2017 | 24,0 |
| | 2018 | 24,0 |
| | 2019 | 39,0 |
| | 2020 | 39,0 |
| | 2021 | 39,0 |
| | 2022 | 39,0 |
| | 2023 | 39,0 |
| | 2024 | 39,0 |
| | Барлыгы | 325,0 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | |

4. «Муниципаль программаның төп максатлары һәм бурычлары» 3 бүлектә:
- «2015-2023» санын «2015-2024» санына алмаштырырга.

5. «2015-2023елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары» бүлегендә һәм програма чаралары буенча финанслашу:
- программа исемендә « 2015-2023» сүзләрен «2015-2024» саннарына алмаштырырга;
- 1.1., 1.2., 1.2.2.-1.2.6., 1.3.-1.5., 2.1.-2.2., 3.1.2.2., 3.1.1. -3.3., 4.1 - 4.5., 5.1.-5.9., 6.1.-6.2., 9.4. «2015-2023» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әтнә муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов